Кемнәр ул Аллаһның әүлияләре?

من هم أولياء الله؟

اللغة التترية

Шәйх Хәйсәм ибн Мөхәммәд Сәрхән

MAHADSUNNAH.COM ALSARHAAN.COM

إن من الناس من يعتقد أن أولياء الله هم أولئك الراقدون في الأضرحة أو تحت القباب.

Кайбер кешеләр Аллаһның әүлияләре үл мавзолейлар яки көмбәзләр сыман төзелгән каберләрдә ятучылар дип үйлыйлар.

وإنما الولي هو المؤمن التقي أيا كان شأنه في الدنيا. فمن كان مؤمنا تقيا كان لله وليا.

Әмма дә ләкин Аллаһның әүлиясе – үл тәкъвалы булучы мөәмин кеше, бу дөньяда нинди генә дәрәҗәдә булуына карамастан.
Һәм кем генә тәкъвалы мөәмин булмасын, димәк үл – Аллаһның әүлиясе.

قال تعالى : ألا إنّ أولياء الله لا خوف عليهم ولا هم يحزنون. الذين امنوا وكانوا يتقون.

Аллаһ әйтте: "Белегезче! Чынлыкта, Аллаһның әүлияләренә һич куркыныч юк һәм алар көенмәсләр. Алар шулардыр ки, кемнәр Аллаһка иман китерделәр һәм тәкъвалы иделәр".

والولي مأخوذ من الولاء وهو القرب فولي الله هو العالم بالله المتقرب اليه بالمواظبة على طاعته المخلص في عبادته.

Әүлия сүзе якынлык сүзеннән алынган. Аллаһның әүлиясе – үл Аллаһны белүче, буйсынуда нык торып Аңа якын булучы һәм ихлас күңелдән гыйбадәт кылучы.

وأولياء الله هم الذين يحبون ما يحبه الله. ويبغضون ما يبغضه.

Аллаһның әүлияләре – алар Аллаһ яраткан нәрсәләрне яратучылар, һәм Аллаһ яратмаган нәрсәләрдән ерак торучылар.

قال النبي صلى الله عليه وسلم : إن أوثق عرى الإيمان أن تحب في الله وتبغض في الله.

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: "Иң көчле иманның элмәге – Аллаһ ризалыгы өчен ярату, һәм Аллаһ ризалыгы өчен нәфрәт хисен кичерү".

واما زعم استغناء الأولياء عن اتباع نصوص الشرعية بما يقع في قلوبهم من العلوم الالهية فكذب وضلال. ولا يشترط ان تظهر على أيديهم الكرامات.

Әмма аларга Аллаһтан ниндидер махсус гыйлем иңү сәбәпле Пәйгамбәребезгә ﷺ иңдерелгән шәригать әмерләренә буйсынмасалар да була дип үйлау – адашу һәм ялган ул. Һәм шулай ук әүлия булыр өчен ниндидер могҗизаларга ия булу да шарт булып тормый.

لذلك قال الائمة لو رأيتم الرجل يطير في الهواء أو يمشي على الماء فلا تغتروا به حتى تنظروا وقوفه عند الأمر والنهي.

Шуның өчен кайбер имамнар әйтте: "Әгәр һавада оча торган, яки су өстеннән йөри торган ир-атны күрсәгез, аның Аллаһның әмерләренә ничек буйсынуын яки тәкъвалыгын күрмичә, аның белән алданмагыз".

وليس لأولياء الله شيء خاص يتميزون به عن عموم الناس من ملابس معينة أو قصة معينة أو غير ذلك.

Һәм Аллаһның әүлияләрен калган кешеләрдән аерып торырлык, бары тик аларга гына хас булган бер нәрсә дә юк: кием булсынмы үл, аерым бер хикәя булсынмы һәм башкалар.

والأولياء ليسوا بمعصومين.

Шулай үк әүлияләр гөнаһсыз да түгелләр.

بل يجوز عليهم الخطأ. ولكنهم لا يصرون عليه.

Аларга да хата-кимчелекләр рөхсәт ителгән, ләкин алар хаталанып гөнаһ кылсалар да, бу гөнаһка чуммыйлар, батмыйлар.

قال النبي صلى الله عليه وسلم :كل ابن ادم خطاء وخير الخطائين التوابون.

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: "Һәр Адәм баласы да хаталы, һәм шулардан иң яхшысы — тәүбә кылучысы".

فالمؤمن الظالم لنفسه معه من ولاية الله على قدر ايمانه.
ومعه من ولاية الشيطان على قدر عصيانه.

Үз-үзенә золымлык кылучы мөәминнең Аллаһка карата булган якынлыгы аның иманының дәрәҗәсе белән бәйле. Һәм шулай ук аның шәйтанга карата якынлыгы, дуслыгы Аллаһның әмерләренә буйсынмау белән бәйле. Ягъни гөнаһлар кылган саен ул Аллаһтан ерагаеп шәйтанга якыная.

وأفضل أولياء الله رسله وأفضلهم محمد صلى الله عليه وسلم خاتم النبيين وامام المتقين.

Һәм Аллаһның әүлияләреннән иң яхшылары – ул Аның илчеләре, һәм алардан иң яхшысы – ул Мөхәммәд ﷺ, илчеләрнең иң соңгысы һәм тәкъвалыларның имамы.

فتولى أولياء الله واحذر من معاداتهم.

Аллаһның әүлияләрен хөрмәт ит, аларга булыш һәм алар белән дошманлашудан сак бул!

فقد قال الله تعالى في الحديث القدسي من عادى لي وليا فقد آذنته بالحرب.

Көдси хәдистә Аллаһ әйтте: "Кем дә кем Минем әүлияям белән дошмашланса, Мин аңа сугыш белдерәм".